РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» марта 2021 г. г. Альметьевск №48

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт шәһәре территориясендә яшел үсентеләр булдыру, аларны тоту һәм саклау кагыйдәләре турында» 2008 елның 27 февралендәге 215 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 19 гыйнварындагы 11/13-09/140 номерлы хаты нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт шәһәре территориясендә яшел үсентеләр булдыру, аларны тоту һәм саклау кагыйдәләре турында» 2008 елның 27 февралендәге 215 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 23 октябрендәге 345 номерлы, 2013 елның 27 сентябрендәге 334 номерлы, 2014 елның 2 октябрендәге 404 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2006 елның 04 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Урман кодексы, 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Дәүләт төзелешенең 1999 елның 15 декабрендәге 153 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе шәһәрләрендә яшел утыртмаларны тезү, саклау һәм тоту кагыйдәләре, «Әлмәт шәһәре территориясендә яшел үсентеләрдән файдалану һәм аларны саклау процессын җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясен

Заказ № 2625

тезекләндерү кагыйдәләре турында» 2019 елның 25 мартындагы 147 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советы карары нигезендә»;

1.2. 3 пунктта ««Әлмәт муниципаль районының Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм тезекләндерү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр»1 нче бүлегенең 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2007 елның 18 маендагы 157 номерлы карары белән расланган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 25 мартындагы 147 номерлы карары белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр» 2 нче бүлегенең 2.2 пунктында «(Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 26 ноябрендәге карары белән расланган)» сүзләрен «(Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2006 елның 23 ноябрендәге 42 номерлы карары белән расланган)» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 1 нче кушымтаның «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда яшел үсентеләрне юкка чыгаруны (яисә) күчереп утыртуны килештерү тәртибе» 9 бүлегенең 9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Яшел үсентеләрне юкка чыгару яки күчереп утыртуны килештерү заказ бирүченең җир кишәрлеген тикшерү турында вәкаләтле орган исеменә язылган хаты нигезендә башкарыла, анда түбәндәге документларны кушып төзү күздә тотыла:

- җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе (проектлаштыру чорына резервлау) яки резервлау актын рәсмиләштерү турында белешмә-хат);

- стройгенплан;

- экология таләпләренә проект документларына дәүләт экспертизасы бәяләмәләренең күчермәләре;

- кагыла торган территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

- төзекләндерү проекты;

- компенсация утыртмалары һәм компенсацияле яшелләндерү һәм күчереп утырту өчен проект сметалары (компенсацияле яшелләндерүне үткәргән очракта).

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турындагы белешмә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына (белешмәләр авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми).

Вәкаләтле орган заказчы белән берлектә төзелеш күздә тотыла торган участокны тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә, анда алынып атылырга тиешле агач һәм куаклар саны, аларның төр составы, агачларның диаметры, торышы, газон, үлән капламы, чәчәк түтәлләренең ведомоство исемлеге күрсәтелә.»;

1.6. 2 нче кушымтаның «Юкка чыгарыла торган яшел үсентеләрнең бәясен билгеләү тәртибе» 4 бүлекнең 4.1, 4.2, 4.3, 4.4, 4.5 пунктларында «(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 28 апрелендәге 154 номерлы карары нигезендә ремонт-төзелеш эшләре өчен ул 3,03 кә тигез)» сүзләрен («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 19 декабрендәге 1169 номерлы карары нигезендә ремонт-төзелеш эшләре өчен ул 7,4 кә тигез») сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм экологик куркынычсызлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов